ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 51-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Н.Н. Хаҗипов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 51-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 205-VII ДС

51-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев,
Н.Н. Хаҗипов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 86 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 47 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 өлешендәге егерме сигезенче һәм утыз җиденче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«21 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары**

Җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнә һәм билгеләнә.».

3) 163 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 296-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законга һәм «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелде, алар җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләү мәсьәләсен хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән. Үзгәрешләр, аерым алганда, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә кагылды.

Шулай итеп, Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләреннән түбәндәгеләр төшереп калдырылды:

калдыклар барлыкка китерү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын, региональ дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) булган объектларда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның (кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан тыш) калдыклар барлыкка китерә торган хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлегенә карата калдыклар барлыкка китерү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын эшләү һәм раслау тәртибен билгеләү;

мондый нормативлар проектларын әзерләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау.

Шулай ук күрсәтелгән Федераль закон белән законнарда кулланыла торган терминологиягә төзәтмәләр кертелде.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы Экология кодексында федераль законнардагы әлеге үзгәрешләрне чагылдыру тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының законнарын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, аларга үзгәрешләр кертүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.